ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» февраля 2024ел № 48

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар мониторингын үткәрү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 29.11.2016 елның 551 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 05.04.2013 елның 44-ФЗ номерлы Федераль законның 97 статьясын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар мониторингын үткәрү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 29.11.2016 елның 551 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Үз көчен югалткан дип танырга:

а) Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр закупкаларына мониторинг уздыру тәртибенең 11 пунктын:

«11. Җыелма аналитик хисап календарь ел нәтиҗәләре буенча әзерләнә (алга таба - хисап елы).».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәриповка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**